| | | |
|---|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ<br>ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

20.06.2019 п.г.т.Алексеевское № 266

**“Инфраструктур үсеш бүлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын раслау турында” Алексеевск муниципальрайоны башкарма комитетының 28.12.2018 ел, 482 нче карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Торак кодексына үзгәрешләр кертү уңаеннан

**карар бирәм:**

1.“Инфраструктур үсеш бүлегенең муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентларын раслау турында”Алексеевск муниципаль районыбашкарма комитетының 28.12.2018 ел, 482 нче карарына үзгәрешләр кертергә һәм торак (торак булмаган) бинаны торак булмаган бинага (торак) күчерү (күчерүдән баш тарту) турында белдерү кәгазе бирү буенча муниципаль хезмәтләр күрсәтү административ регламентындагы 2.5 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

1) Бинаны күчерү турында гариза;

2) күчерелә торган бинага хокук билгеләүче документлар (төп нөсхәләр яки нотариуста расланган күчермәләр);

3) техник тасвирламасы белән күчерелә торган бина (әгәр күчерелә торган бина торырга яраклы булса, андый бинаның техник паспорты);

4) күчерелә торган бина урнашкан йортның һәр катының планы;

5) күчерелә торган бинаны яңартып төзү һәм (яки) яңадан планлаштыруныңбилгеләнгән тәртиптә әзерләнгән һәм теркәлгән проекты (әгәр яңартып төзү һәм (яки) яңадан планлаштыру андый бинаны торак яки торак булмаган бина сыйфатында файдалану өчен таләп ителсә);

6) күп фатирлы йортта бина хуҗаларының торак бинаны торак булмаган бинага күчерүгә ризалыклары турында карар язылган гомуми җыелышы беркетмәсе;

7) күчерелә торган бинага орынып торучы барлык биналар хуҗаларының торак бинаны торак булмаган бинага күчерүгә ризалыгы.

2. Әлеге карарны ТатарстанРеспубликасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырырга һәм Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне инфраструктур үсеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.Н. Абакумовка йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К. Кадыйров**